# Ислам нуры

«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәту бар»
(Коръән Кәрим. 2-256)

12+

№ 4 (680) 26 февраль 2019 ел (1440, Җөмәдел-ахир) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга


## Остаз вә мөгаллим



Остаз вә мәктәп җитәкчеләре сезнең эшегезне юлына куючылар вә сезнең өчен хәсрәт чигүчеләр булып, аларның сезнең өстегездә олы хаклары бардыр. Шуның өчен аларның кушканнарын җиренә җиткерүдә кимчелек эшләмәгез вә тыйган эшләрендә әвәләнмәгез! Сөйләшкән вакытыгызда алар белән әдәпле сөйләшегез, артык кычкырмагыз, аларны алдап вә бер кешене гайбәт итеп бер дә сөйләмәгез! Аталарыгыз тәннәрегезне тәрбияләп үстергән хәлдә, остазларыгыз җаннарыгызны тәрбия итеп үстерәләр. Бу сәбәпле остазларыгыз — бөек аталарыгыздыр. Сез дә боларны чын күңел белән сөегез, нәсыйхәтләрен тыңлагыз, авыруларның табибларга тапшырылуы кебек, барлык ихтыярыгызны аларга тапшырыгыз, аларның теләкләренә каршы килмәгез! Мөгаллимнәрегезгә түбәнчелекле булыгыз, каршыларында әдәпле утырыгыз, нәсыйхәтләре белән гамәл кылыгыз, саваплы булыр өчен хезмәтләрен җиренә җиткерегез, аларга ялыныгыз, башка урында ялыну — мөэмин-мөселманга хас булмаган хәлдә, гыйлем өйрәнү тугрысында ялыну — мөэмин-мөселман сыйфатыдыр. Мөгаллимнәргә каршы килмәгез, алар белән кычкырышмагыз, һәрбер гүзәл эшләрдә аларның сүзләренә җан вә тән белән иярегез. Ләкин аңламаган урыныгыз булса, шул хәленчә калдырып китмичә, бәлки әдәп вә сабырлык белән: “Әфәндем, бу җирне аңламадым вә бу сүзне белмәдем», — дип кайтарып сорагыз! Мөгаллимнәрегез яки мәктәп җитәкчеләре яныгызга килгәндә, әдәп вә хөрмәт белән каршы алыгыз, әгәр дә берәр төрле сүз сорасалар, сүзегезне үлчәп кенә, яхшы җавап бирегез! Дәресләрне бертөрле тәмамлагач, мәктәптән аерылганыгыздан соң, мөгаллимнәр вә мәктәп җитәкчеләренең вә мәктәпне тәрбия итүчеләрнең хезмәтләрен хәтерегездән чыгармагыз, очраган вакытларында хөрмәт күрсәтүдә кимчелек җибәрмәгез. Һәр намаз соңында алар өчен хәер-догада булыгыз!

*(Риза Фәхреддин. “Әхлак гыйлеме”)*

## Чаллы яңалыклары

**14** февраль көнне шәһәрнең “Нур-Ихлас” мәчетендә Чаллы имамнарының бу елны беренче җыелышы булды. Ул “Утыз Имәни” мәчете имамы Инсаф хәзрәт Сәүбановның Коръән укуы белән башланып китте. Җыелышның беренче яртысында балаларның Коръән уку бәйгесе, татарча көрәш һәм кул көрәше буенча турнир хакында сөйләштеләр. 27 һәм 30 март көннәрендә уздырылачак бу ике чара өчен, үткән еллар тәҗрибәсен истә тотып, катнашучыларны сайлап алу кагыйдәләре кабул ителде һәм хөкемдарлар сайланды. Мәҗлеснең икенче яртысында моргта мәетләр белән эш итү һәм мәчетләрдә янгын куркынычсызлыгы турында фикер алышынды. Шулай ук бу елны мәчетләрдә үткәреләчәк дәрес темалары һәм планлаштырылган яңа проектлар турында да сүз барды. Мәҗлес ахырында “Ихлас” мәчете имамы Илгиз хәзрәт Сөнгатуллин хәзрәтләрне “Ихсан” хәйрия фондының 2018 ел эшчәнлеге белән таныштырды.

***

**17** декабрь көнне “Тәүбә” мәчетендә хәләл ризыкка багышланган дәрес уздырылды. Билгеләнгән теманы халыкка кызыклы рәвештә аңлату һәм сорауларга җавап бирү өчен ТР МДН “Хәләл” стандарт комитеты вәкиле Курмалеев Габдерәшит хәзрәтне һәм Түбән Кама шәһәре кунагы Ибраһимов Фәнил хәзрәтне чакырганнар иде. Чараны “Тәүбә” мәчете имамы Айгиз хәзрәт спикерлар белән таныштырып һәм хәләл ризык темасына бәйле видеоязмалар күрсәтеп башлап җибәрде. Габдерәшит һәм Фәнил хәзрәтләр исә үз чыгышларында җыелган тыңлаучыларны Чаллы шәһәрендә “Хәләл” стандарт комитеты эшчәнлеге белән таныштырып киттеләр. Шулай ук христиан халкы чалган итне кулланырга, кафелардагы хәләл тавык итеннән ясалган ризыкларны авыз итәргә ярыймы-юкмы икәнен аңлаттылар. Дәрес ахырында хәләл йомырка, тоз, дарулар составында булган желатин һәм спиртка бәйле сорауларга да җавап бирделәр.

***

**19** февраль көнне Җәмигъ мәчете төзелеше Попечительләр шурасының чираттагы җыелышы булды. Аның барышында 2017-18 еллар эчендә башкарылган төзелеш эшләренә нәтиҗә һәм финанс керем-чыгымына хисап ясалды. Җыелыш ахырында 2019 ел өчен якынча план төзелде.

## ТР МДН хәбәр итә

Җөмәдел ахыр аеның 14нче көнендә, Алабуга шәһәренең Җәмигъ мәчетендә «Яшь вәгазьче» дип исемләнгән IV республикакүләм дини бәйгенең финалы уздырылды. Конкурс ТР мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан, яшь вәгазьчеләр әзерләү, шулай ук яшьләр арасыннан сәләтле татар мөселман нәфис сүз осталарын ачыклау, аларның иҗади мөмкинлекләрен үстерү һәм халык алдында чыгыш ясарга өйрәтү максатыннан оештырылды. Анда Татарстанның төрле районнарыннан 15 яшьтән 35 яшькә кадәрге 30дан артык егет һәм кыз катнашты. Бәйгегә имамнар, хәзрәтләр һәм мөгаллимнәр кертелмәде. Чыгышларны мәртәбәле жюри – Алабуга районы имам-мөхтәсибе Хәлим хәзрәт Шәмсетдинов, Азнакай районы имам-мөхтәсибе Азат Талибуллин, Менделеевск районы имам-мөхтәсибе Ирек хәзрәт Нуриев, Кукмара районы имам-мөхтәсибе Рәдиф хәзрәт Тимергалиев, «Шура» журналының җаваплы сәркатибе Рәмзилә Шәфыйкова, Алабуга мөхтәсибәтенең хатын-кызлар белән эшләү бүлеге җитәкчесе Лилия Фазлыева бәяләде.

Бәйге нәтиҗәләре буенча абсолют җиңүче исемен Азнакайдагы сәүдә үзәге җитәкчесе, 34 яшьлек Рөстәм Шакиров яулады. “Мөхәммәдия” мәдрәсәсе шәкерте, Казан дәүләт энергетика университеты студенты - 23 яшьлек Саба егете Альмир Исмәгыйлев II урынга лаек булды. III урында – Әгерҗедән 25 яшьлек Инзилә Мазикова. Җиңүчеләргә кыйммәтле бүләкләр, барлык катнашучыларга сертификатлар тапшырылды.

Бәйгедән соң катнашучылар өчен Алабуга мөхтәсибәте тарафыннан Алабуга шәһәре тарихы музеена экскурсия оештырылды.

## “Ихсан” фонды

Чаллы мөхтәсибәте каршында эшләп килүче “Ихсан” фонды тарафыннан ялгыз аналар һәм аларның балалары өчен “МамаМожет” дигән хәйрия чарасы оештырылган иде. Чираттагы очрашу барышында әниләр өчен “Как восполнить ресурсы” дигән темага семинар, “Секреты уюта” дип аталган мастер-класслар үткәрелде. Әниләр шул рәвешле мәшгуль булган арада, “Сәйлән” балалар клубы остазлары кечкенәләрне матур-матур чәчәкләр ясарга өйрәттеләр. Әлеге чәчәкләр әниләр өчен менә дигән бүләк булды. Бу чараны оештыруда ярдәм күрсәткән һәркемгә Алланың рәхмәтләре булсын. Алла боерса, мондый чаралар ай саен уздырылыр дип көтелә.

“Ихсан” хәйрия фонды “Чаллы балалар йорты”нда тәрбияләнүче, дөньяга аваз салган көннәреннән үк ата-ана назыннан мәхрүм калган сабыйларга да ярдәм чаралары оештырды.

Мондый игелекле проектларда теләге булган һәркем катнаша ала.




# Мәчетләрне хөрмәт итү

*Әлхәмдулилләһи раббил гааләмиин. Вәссаләәтү үәссәләәмү гәләә расүүлинә Мүхәммәдиү вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгиин.*

*Барча галәмне юктан бар кылучы, Раббыбыз Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгаләгә хәмде-сәнә, мактауларыбыз, сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (с.г.в.) гә күңелебезнең түреннән чыккан салават шәрифләребез булса иде һәм дә аның әһле бәйтенә сәламнәребез ирешсә иде. Раббыбыз Аллаһуның әмерен үтәп, Аның рәхмәтләренә ирешергә насыйп булсын. Мөселман кардәшләрем, әс-сәламү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәракәтүһ. Һәрберебезгә дә Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгаләнең сәламе, ике дөнья рәхмәте һәм бәрәкәте булсын!*

Раббыбыз Аллаһы Тәгалә әйтә: "Ул яктылык бирүче шәм мәчетләрдә булыр, Аллаһ боерды ул мәчетләрне зурларга һәм Аллаһ исемен зекер итәргә, ул мәчетләрдә Аллаһуга тәсбих әйтерләр иртәләрдә һәм кичләрдә". (24 Нур, 36) Икенче бер аятьтә: "Алыш-биреш итеп сәүдә эшләренә алынмый торган ирләр, аларны алдый алмады дөнья эше, Аллаһ зекереннән, намаз укудан һәм зәкят бирүдән, алар күңелләр һәм күзләр тетрәгән кыямәт көненең катылыгыннан куркалар". (24 Нур, 37)

Ошбу аятьләрдә Раббыбыз Аллаһ мәчетләрнең нигә кирәклеген аңлата: дөнья эшенә алданмыйча, сәүдә эшләрен калдырып торып, Анда Кыямәт көненең катылыгыннан күңелләре һәм күзләре курыккан ирләр өчен, Аллаһны зурлап, зекер әйтеп намаз уку өчен кирәк мәчетләр.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (с.г.в.): "Кешеләр мәчетләр белән мактаныша башлаганчы Кыямәт купмас", – дип әйткән. Мәчетләрнең зурлыгы, матурлыгы, байлыгы, манараларның биеклеге һәм башка шуның кебек әйберләр белән мактанышу хәзерге вакытта мөселманнар арасында киң таралган һәм бу сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (с.г.в.) әйткәнчә, Кыямәт якынлашуның билгесе. Ягъни Пәйгамбәребез (с.г.в.) безгә, "мәчетләрегез белән мактанмагыз һәм аларны бизәмәгез", дигән, ә бит мәчетне бизәүче һәм матурайтучы булып халыкның анда күп йөрүе тора. Мәчетләр белән мактанышулар Аллаһның хак дине булган Ислам диненә каршы килә, чөнки мәчетләр – Аллаһка гыйбадәт кылу өчен генә билгеләнгән йортлар.

Хәдистә: "Мәчетләр Аллаһны зекер итәр өчен һәм намаз укыр өчен төзелде", – дип әйтелә.

Хәбәр итүләре буенча, Язид Әл Кинди сөйләгән: "Гомәр (аннан Аллаһ разый булсын) хәлифә булган вакытта, мәчеттә тавыш күтәреп сөйләшүләрен ишеткәч, Гомәр ибн әл Хаттаб миңа: "Теге икәүне китер әле", – диде һәм мин ул әйткән ике кешене чакырып китердем. Алардан: "Сез кем?" – дип сорагач, үзләрен Таиф шәһәреннән булуларын әйттеләр. Гомәр әйтте: "Әгәр Мәдинә әһелләреннән булсагыз, сезгә җәза бирер идем, Аллаһның илчесе мәчетендә нигә тавышысызны күтәрәсез? Кайда икәнегезне белмисезме әллә?!" Ягъни, Гомәр хәлифә булган вакытта, тавышланырга ярамый икәнен белеп тә, мәчеттә тавышланган кешегә суктырып җәза бирү каралган булган.

Мөселман кеше мәчеткә кергәндә: "Әй Аллаһ, миңа рәхмәт ишекләреңне ач"; ә мәчеттән чыкканда: "Әй Аллаһ, миңа фазыйләт ишекләреңне ач", - дип дога кылырга тиешле икәнен Пәйгамбәребез (с.г.в.) өйрәтеп калдырган.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә: "Коръән укылганда яки Коръәннән вәгазь сөйләнгәндә ихлас тыңлагыз, сүз сөйләшмичә, эш эшләмичә тик торыгыз! Шулай итсәгез, шаять, рәхмәт кылынырсыз", – ди. (Әгъраф, 7/204)

Коръәни Кәрим намаз вакытында укылса да, намаздан тыш укылса да, аны тыңлау һәм тыныч тору ваҗиб була. Мәчеттә гыйбадәттән башка эшләр белән шөгыльләнү, сөйләшеп утыру, хәтта сөйләшмичә утырып та Коръәнне тыңламау – Аллаһы Тәгаләнең әмеренә каршы килүне аңлата.

Аллаһы Тәгалә әйтә: "Әйт: Раббым һәр эштә гадел булырга әндәп әмер бирде һәм мәчеттә йөзләрегезне кыйблага юнәлдерегез һәм динне Аллаһ ризалыгы өчен генә ихлас тотып, Аңа гына гыйбадәт кылыгыз, Ул сезне әүвәл ничек яраткан булса, шулай ук Аның хозурына кайтачаксыз". (Әгъраф, 29).

Икенче бер аятьтә: "Әй Адәм балалары, намаз укый торган урынга барганда, һәрвакыт гаурәтләрегезне каплар өчен пакъ киемнәр киегез; ашагыз, эчегез, ләкин исраф кылмагыз, Аллаһ исраф кылучыларны сөйми". (Әгъраф, 31).

Хәдисләрдә әйтелә: "Әгәр бер кешенең мәчеткә даими йөрүен күрсәгез, аның иманлы булуына шаһитлек бирегез".

"Әгәр Аллаһы Тәгалә бер кавемгә чир җибәрергә теләсә, мәчет әһелләренә карар һәм ул бәлане кире кайтарыр".

Мәчетләр булу, ягъни Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылу өчен төзелгән мәчетләр булу сәбәпле, күп бәлаләр китә. Әгәр дә мәхәллә халкы даими намазга йөрсә. Ә инде мәчетләр булып та, намазга йөрүчеләр булмаса, кайгы-хәсрәт китми, киресенчә, арта гына.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (с.г.в.) әйткән: "Сарыкларның бүресе булган кебек, шайтан – кешенең бүресе, бүре көтүдән аерылган һәм читтә йөргән сарыкларны ала. Берүк аерылудан сак булыгыз, җәмәгать белән, күпчелек белән һәм мәчетләр белән бергә булыгыз!"

Аллаһы Тәгалә әйтә: "Барча мәчетләр дә бары тик Аллаһка гыйбадәт кылу урыны, шулай булгач, Аллаһудан башкага гыйбадәт кылмагыз һәм кәферләргә дога кылмагыз һәм бидгать гамәлләрне эшләмәгез". (72 Җен, 18)

Сәхабәләр әйткән: "Мәчетләр – Аллаһының җирдәге йортлары. Үзенә гыйбадәт кылырга мәчеткә килүчене Аллаһ, әлбәттә, хөрмәт кылыр". Ягъни, мәчеткә йөрүчеләргә Аллаһы Тәгалә Үзенең дөнья һәм ахирәт нигъмәтләрен бирә. Мәчетләрдә золым кылу ярамаган кебек, башка кешеләргә намаз укырга, Коръәни Кәрим укырга, зикер кылып утырырга комачау итмәс өчен, пышылдап сөйләшү дә тыела.

Без мөэмин-мөселманнар буларак, сөекле Пәйгамбәребез (с.г.в.) сөннәтенә ияреп, Аллаһы Тәгаләнең әмерен үтәп, мәчетләргә җәмәгать намазына, кылган гыйбадәтләребезнең әҗер-саваплары күбрәк булсын дип киләбез. Мәчетләрне хөрмәт итү турында Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте: "һәркайчан сезнең берегез икенде яисә иртәнге намазын укыганнан соң мәчеткә керсә, намаз уку тиеш булмас. Чөнки бу вакытта намаз уку тыелды. Ләкин бу бәндә тәсбих әйтер, ягъни "Сөбхәнә-ллаһи", дип әйтер, янә тәһлил әйтер, ягъни "Ләә иләһә иллә Аллаһ" дип әйтер, һәм "Аллаһүммә салли галәә сәййидинәә мүхәммәдин үә галәә әәли сәййидинәә мүхәммәд", дип Пәйгамбәребез (с.г.в.)гә салават әйтер, һәм ул намаз фазыйләтенә ирешер, янә мәчет хакын үтәде".

Мөселман кеше мәчеткә кергәч, иң беренче гамәле - сөннәт буларак тәхиятүл, ягъни мәчет намазын укый. Бер мәчеткә карап чыгу өчен кергән кешегә мәчет намазы уку тиешле. Әмма икенде һәм иртәнге намазларын укыганнан соң, ошбу ике намазның вакыты чыкканчы мәчеткә керсә, тәхиятүл – мәчет намазын укымый. Чөнки бу вакытта шәригать буенча намаз уку тыелган. Бу вакытта мәчеткә кергән кеше тәсбих, тәһлил, Пәйгамбәребез саллАллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтсә, мәчет намазын укудан алган кадәр әҗер-савабын ала. Әйткән зекерләре белән мәчет хакын да үти. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (с.г.в.)нең иптәше Хәким бин Гомәйр әйтте: "Дөньяда кунак булыгыз. Мәчетләрне йортлар итегез. Күңелләрегезгә йомшаклыкны өйрәтегез, уйлау белән елауны күбәйтегез. Сезгә күңел теләкләре катнашмасын".

Безләргә әйтә, дөньяда вакытта Аллаһы Тәгаләдә кунакта икәнебезне онытмыйча, тыйнак булырга, ди. Мәчетләргә даими йөрергә кирәк, гаеттән гаеткә генә түгел, шулай ук җомгадан – җомгага гына да түгел, ә көн саен намазларга йөреп, Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы өчен гыйбадәт кылырга куша.

Кеше йортына керсәк, үзебезне ничек яхшы итеп тотарга тырышабыз! Ә галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһы Тәгаләнең йортларына керсәк, без үзебезне ничек тотарга тиеш соң?! Әлбәттә, күпкә әдәплерәк, тыйнаграк һәм бөек Аллаһ каршында мескен бәндә һәм Аның колы икәнебезне тоеп керергә тиешбез.

Хәдистә: "Җир йөзендә Аллаһка иң сөекле урыннар – мәчетләр, иң сөйкемсез урыннар - базарлар", диелә.

Раббыбыз Аллаһ мәчетләрдә вакытыбызны күбрәк Үзенә гыйбадәт кылып үткәрергә насыйп әйләсен. Әмин!

**Равил хәзрәт НУРУЛЛИН.**
**Чаллы шәһәренең "Туфан" мәчете имам-хатыйбы**

## СОРАУ-ҖАВАП

*Укучылардан килгән сорауларга шәригать белгече Рәфыйк хәзрәт МИННӘХМӘТОВ җавап бирә.*

**Сорау.** Мәетне юганчы, кәфенләгәнче дога уку дөресме?
Мәетне юганчы, кәфенләгәнче Коръән уку дөресме?

Фәнис, Чаллы шәһәре.

**Җавап.** Мәетне юганчы, кәфенләгәнче дога уку дөрес. Мәетне юганчы, кәфенләгәнче анын янында Коръән уку ярамый, юылган һәм кәфенләнгән булса – ярый.

**Сорау.** Ислам динендә ата-ана хакы, бала хакы дигән төшенчәләр бар, ә менә мөгаллим хакы дигәне бармы? Бүген дөньяви мәктәпләрдә укучы һәм мөгаллим арасындагы ызгышлар турында, ул ызгышларны интернетка, халык арасына чыгару турында еш ишетәбез. Балаларның мөгаллимгә карата булган мөнәсәбәтенә шаккатабыз, олыны олы итү дигән нәрсә онытылып бара шикелле...

Зәкия Галиева, Казан шәһәре.

**Җавап.** Ислам динендә бөтен нәрсә әдәп-әхлак кагыйдәләренә нигезләнеп алып барыла, гыйлем эстәүченең дә, гыйлем бирүченең дә дәрәҗәсе югары. Хәдис буенча, галимнәр - пәйгамбәрләрнең варислары диелә. Үзеңә гыйлем биргән, изгелек кылган кешегә рәхмәтле булу, шөкер итү - шәкертнең бурычы. Ә инде дөньяви мәктәпләрдә укытучыга карата тупас мөнәсәбәт, ыгы-зыгылар - ул безнең җәмгыятьнең проблемасы. Ул проблемалар балалар бакчасыннан ук башлана. Барысы да, әйткәнемчә, әдәп-әхлак кагыйдәләренә барып тоташа. Бала кечкенәдән Алла хакы, ата-ана хакы, күрше хакы турында ишетеп, шул рухта тәрбияләнеп үссә, әлеге проблемалар булмас иде. Мөселман җәмгыятендәге укыту системасында мондый проблемалар юк бит. Әхлакка мөнәсәбәтне үзгәртми торып, бу катлаулы мәсьәләләр тиз генә үзеннән-үзе хәл ителмәячәк.

# Бәхәстән тыела бел

Юл куючы - ул нәфесен, мин-минлеген җиңүче. Кызганыч, кайвакыт шуңа да акылыбыз җитми һәм без шайтан колларына булабыз. Шайтан безгә: «Син үзең белгәнчә аңлат, бирешмә, чигенмә», - дип, «акыллы» нәсыйхәтләрен биреп тора. Һәм безнең фикер тарлыгы, яхшыга өндибез дигән купшы уй булып, гөнаһка этәрә. Берүк шайтан вәсвәсәсенә бирелеп, аңа өстен чыгарга юл куймыйк, мәгънәсез бәхәстән шайтан гына ота, ул гына куәт ала. Үз сүзеңне таныту ул - бәлки, яхшыдыр, әмма иң элек син күркәм сүз, яхшы вәгазь белән кешедә хакыйкатьне тану теләге уятырга тиеш. Әгәр бу эшне булдыра алмыйсың икән, хакыйкатьне аңлатырга тырышу җәнҗал белән, тавыш белән тәмамланырга мөмкин, әлбәттә инде, зыяны файдасыннан күбрәк була. Бәхәсләшергә яратучы өчен иң зур дәгъвәт - дәшми тору. Бәхәсләшергә яраткан яки бәхәсләшергә өйрәткән галимнәрдән, арысланнан качкан кебек, читләшү хәерле. Юк-бар бәхәс ул кешеләрнең дә, Аллаһның да нәфрәтен уята.

***Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ,***
***Татарстанның баш казые.***

# МӘЧЕТТӘ ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ

Мәчет – гыйбадәт урыны. Гыйбадәтне оештыру – мәчеттә хезмәт күрсәтүчеләрнең бурычы, вазыйфасы. Аллага шөкер, шәһәребездә мәчетләр шактый, алар эшли. Ислам дине канунннарына муафыйк булган вазыйфалар башкарыла: һәр көнне биш вакыт намаз үтәлә, гаилә төзергә теләге булганнарга никах укыла, исем кушыла. Кешене соңгы юлга озатуны да мәчет оештыра.

Чулман елгасыннан ерак булмаган бер урында, яшел түбәле, мәһабәт манаралы, җыйнак кына бер мәчет бар. Тыгыз гына урнашкан йортлар арасында ул. Бер ягында балалар бакчасы, икенче ягында мәктәп. “Рамазан” мәчете.

Көн саен биш мәртәбә әйтелә торган азан шәһәр киңлекләреннән чыгып, Чулман елгасы яры буйлап тарала. Шул бәрәкәтле йортта ел әйләнәсенә халыкка рухи хезмәт күрсәтелә. Ел тәмамлануга, мәчетнең имамы мәчет әгъзаларын җыелышка җыя. Шундый җыелышларның берсе февраль уртасында оештырылды. Җыелышка Чаллы шәһәре мөхтәсибәтеннән дә кунаклар чакырылган иде. Әлфәс хәзрәт бу өлкәдәге күпьеллык тәҗрибәсе белән уртаклашты. Мәчетнең имамы Илдар хәзрәт Галиуллин, мәчет хезмәткәрләре белән тагын бер мәртәбә үткәннәргә йомгак ясап, киләчәккә ирешелергә тиешле максатларны билгеләделәр.

Һәр эшнең үзенең мактаулы һәм ирешелергә тиеше яклары бар. Шунсыз үсеш тә, үзгәреш тә була алмый. Илдар хәзрәт әйтүенчә, мәчеттә шактый эшләр эшләнгән. Мәчетнең эчке ягы төзекләндерелгән, тәһарәтханә яңартылган, намаз уку залы матурландырылган, хатын-кызлар өчен махсус намаз уку залы булдырылган. Боларны санап чыгу өчен бармаклар гына җитми. Бу эш химаячеләр һәм сәдака хисабына эшләнә. Мәчетнең айлык чыгымнары арендага алып торучы кибет хисабына каплана. Хәзрәтнең киләчәккә планнары зур, максатчан. Бу, беренче чиратта, уку-укыту эшен җайга салу. Мәчеттә дини, рухи гыйлем бирү эшен дәвам итү, дини һәм шул ук вакытта дөньяви гыйлемгә дә ия булган укытучыларны җәлеп итү – хәзрәтнең иң зур хыялы. Моның өчен уку-укыту бүлмәләрен җиһазлау, уку әсбаплары туплау мөһим.

Халыкка дини-рухи хезмәт күрсәтү юлында хәзрәтнең ярдәмчеләре дә күп. Алар - тормыш тәҗрибәсе җыйган аксакаллар, эшмәкәрлек белән шөгыльләнүчеләр, акыллы киңәшләре белән ярдәмгә килүчеләр, кул хезмәте белән ярдәм итәргә ашкынып торучы хөрмәтле кешеләр. Инде ничә еллар Хаҗи бабай, Фоат абый, Наил абый, Шамил абый, Тәлгать абый, Фәрит абый, Булат – хәзрәт ярдәмчесе (барысын да санап бетерү мөмкин түгел) һ.б. игелекле хезмәтен куя. Мәчетнең иң кирәкле эше Дания Миннегуловага йөкләнә. Ул мәчеткә килгән сәдаканың санын, исәбен алып бара.

Мәчет – кешеләрнең һәрдаим килеп китү урыны да. Чисталыкны саклау һәм тәртиптә тоту – Миңниса апа өстендә. Якты чиста тәрәзәләр, вакытында суыртылган йомшак келәмнәр, матур чәчәкле гөлләр – аның хезмәте. Бу очракта Әлфәс хәзрәтнең: “Мәчеткә килгән кеше кире әйләнеп килерлек булырга тиеш”, – дигән сүзләре белән килешмичә мөмкин түгел.

Аллаһның ярдәме белән, Чулман елгасыннан ерак та булмаган “Рамазан” мәчетендә яшәеш дәвам итә. Ул шул мәчеттә хезмәт күрсәтүче фидакарь кешеләр хезмәтенә, кулга-кул тотынып эшли белүчеләр, татулыкка, бердәмлеккә нигезләнә.

**Г. НАСЫЙБУЛЛИНА.**

# Күңел тәрбиясе

– Йә Аллам, никләргә генә бу биремне бирдем икән, никләргә генә эшләттем икән бу күнегүне, – дип сукрана-сукрана, бер кочак дәфтәр кочаклап, 8 нче сыйныфның татар теле укытучысы Гөлнара Наилевна укытучылар бүлмәсенә килеп керде. “Нәрсә булган?!” дигән караш ташларга да өлгермәгән укытучылар алдында зарларын сөйләп китте.

– Программа нигезендә тыныш билгеләре темасын кабатлыйбыз. Дәреслектә тема ахырында биремле күнегү. Биремендә - үзең белгән ике классташыңа чагыштырма характеристика язарга. Аларның охшаш яки аермалы якларын тасвирларга диелгән. Нәрсә генә язмаганнар бу балалар! Бер-берсеннән бөтен үчләрен алганнар. Сигез ел бер класста укып, бер икмәкне ашап, бер кичерешләр белән яшәгән балалар шулхәтле бер-берсен рәнҗетерлек сүзләрне каян табып бетергәннәр, – дип дәвам итте ярсуын кая куярга белмәгән укытучы.

Бу хәбәрдән соң тәрәзә янындагы диванда “Күңел тәрбиясе” дигән китап укып утыручы Гөлшат Локмановнаның уйлары моннан байтак еллар элек булган хатирәләрне яңартты.

Уку еллары совет заманы дигән чорга туры килде аларның. Галстук бәйләп, значок тагып йөргән заман. Вахтага утырып җыйнаулашып мәктәпкә килүләр. Дәрестән соң калып идән юуулар. Теплицада бергәләп чәчәк үстерүләр. Мәктәпне тәмамлап, шул ук мәктәпкә эшкә кайтып эшли башлаганына да 15 ел тулган икән. Бүгенгедәй хәтерендә. Укытучылары, республиканың танылган методисты, дәреслекләр авторы Илдус абыйлары “Классташым” темасына сочинение язарга биргән иде. Югары сыйныф укучылары. Зурлар. Чәч агартып, керфек, каш буяп, ирен кызартып, итәк кыскартып йөри башлаган чаклары. Ап-ачык хәтерли. Класста бик тә матур, модалы киенергә яратучы Рузилә Ибраһимова бар иде. Кыз кеше бит, матур буласы килгәндер инде. Аның турында язмыйча булмый бит!? Рузиләнең чәче Резидәнекенә караганда аграк, чөнки ул аны атна саен буйый. Раушан Равилдән озынрак, чөнки.... Нәрсә язганын искә төшерә алмады Гөлшат. Раушан химияне яхшы белә, чөнки аның әнисе химия укытучысы. Лилиянең итәге кыска, чөнки аяклары матур!

Уйларыннан елмаеп куйды Гөлшат Локмановна.

Шуннан соң класста дуслык артты, кыска итәкләр тиздән түбән төште, класстагы бөтен укучылар диярлек химиядән тырышып укый башлады.

«Гөлнара Наилевна, сезнең класстан ике малай сугыша, берсе ник минем чәчемне озын диде, синең нинди эшең бар, дип разборка ясыйлар», – дигән хәбәр аны уйларыннан айнытты.

Кеше күңеле һәрвакытта матурлыкка омтыла ул. Кимчелектән сабак ала. Дәреслектә бирелгән биремнәр дә, грамматиканы үзләштерү өчен генә түгел, күңел тәрбиясе бирү өчен дә куела бит...

**Гөлфия НАСЫЙБУЛЛИНА.**

ӘДӘБИ СҮЗ

# Кышкы дөнья

Аллаһының киң кодрәте белән,
Акшарланган йөзе дөньяның.
Баетырга рухи байлыгымны,
Ап-ак урамнарны урадым...
Аһ син, дөнья,
Кышкы сихри дөнья,
Ак чагында нинди серле син!
Гаҗәпләнеп, туктап карап тордым,—
Фасыл саен төрле төсле син.
Күпме сафлык,
Күпме матурлыклар,
Күпме пакьлек ята ак җирдә.
Өстәвенә, яуган кар өстенә
Алтын кояш нуры сибелә.
Әсир итте кышкы матурлыгың,
Әсир итте дөнья аклыгы.
Күпме сихәт, дәва ала кеше,
Синең бу аклыгың аркылы.
Карлар төшә...
Җиргә иңәр өчен,
Ашкыналар микән шултикле?
Чыршы канатында авыр бәсләр,
Гүя мамык мендәр шикелле.
Аһ син, дөнья,
Гаҗәп матур дөнья,
Һәр фасылда ямьле, үзгә син!
Нинди төскә Ходай бизәсә дә,
Искитмәле, чиксез гүзәл син!..

***Роберт Сәлахиев,***
***Актаныш районы,***
***Тат. Суыксу авылы.***

# Имам Газалиның хикмәтле нәсыйхәте

Үз улына нәсыйхәт биреп, имам Газали болай дигән: “Йә улым! Нәрсә генә булса да, барысы да Аллаһның тәкъдире белән була. Кемнедер Ул бай иткән, кемнедер – фәкыйрь, кемнедер сәламәт яраткан, ә кемнедер гарип итеп бар кылган, кемнедер белемле иткән, ә кемнедер надан... Бу дөньяның төзеклеге нәкъ менә шулай саклана. Ләкин шуны гел истә тот, улым:

Әгәр син үзеңнән түбәнрәк дәрәҗәдә булган кешеләрне очратсаң, аларны түбәнсетмә, мыскыл итмә һәм масаеп, үзеңне горур тотма, чөнки синең алар урынында, ә аларның синең урында булуы да мөмкин иде бит. Шул хакта уйланып, шундый кешеләр белән дус-тату бул, алар белән аралашканда, тыйнак булырга тырыш, кешелеклек белән динилегеңне сакла. Шулай итсәң генә бәхеткә ия булырсың...

Бу дөнья һәм ахирәт өчен тынычлык сора – аның өчен беркемне дә рәнҗетмә! Әгәр үзеңнән яшьрәк кешене күрсәң: “Аның гөнаһлары минекенә караганда азрак”, – дип әйт. Өлкәнрәкне күрсәң: “Аның изгелекләре минекенә караганда күбрәк һәм ул кешедә, бәлки, мин белмәгән әллә нинди яхшы сыйфатлар бардыр”, – дип уйла.

Әгәр галим кешене күрсәң, эчеңнән генә: “Аның гыйлеме бар һәм шуның ярдәмендә ул үзен коткарачак”, – дип уйлап куй. Ә үзеңнән азрак белгән кешене очратсаң: “Бәлки, Аллаһы Тәгалә аны белмәгәне өчен гафу итәр”, – диген.

Хәтта динсезне, кяферне очратканда да: “Белеп булмый, бәлки, Аллаһ аны гафу итеп, аңа ихлас иман бүләк итәр һәм ул Раббысы каршына пакь, чиста килеш килеп басар...” – дип уйла.

Никадәр үзеңне яхшырак өйрәнеп, хаталарыңны аңласаң һәм үзеңне башкалардан гөнаһлырак тойсаң, Аллаһ каршындагы дәрәҗәң шул кадәр югарырак булачак...

**Ришат хәзрәт КУРАМШИН әзерләде.**

# Оясында ни күрсә...



*Бүгенге көндә Берләшкән Гарәп әмирлекләрендә яшәүче җәмәгать эшлеклесе, эшмәкәр Исмәгыйль Каләметдин улы ШӘҢГӘРӘЕВ хакында ишетмәгән кеше сирәктер. Ислам диненә ихтирамлы мөнәсәбәте, чит җирләрдә милләттәшләребезне туплап торуы, дин һәм җәмгыять өлкәсенә караган саллы-саллы хезмәтләре нигезендә нилər ята? Дубайга баргач, күрешкән мәлебездә Исмәгыйль әфәндегә шул сорауларны бирергә ашыктык.*

**- Исмәгыйль әфәнде, нәсел чыгышыгыз белән сезнең Оренбург өлкәсеннән икәнне беләбез. Ә менә нинди җилләр ерактагы Гарәп Әмирлекләренә алып килде үзегезне? Сер булмаса, гаиләгез белән монда төпләнүегезнең сәбәбен дә әйтсәгез...**

- Бер дә сер түгел. Беренчедән, монда һава торышын беләсез, бик җылы, диңгез буе - балалар өчен шунысы яхшы. Икенчедән, биредә мәчетләр адым саен, өченчедән, ризыкның барысы да хәләл. Минем әти мулла иде бит, без гаиләдә кечкенәдән татар, мөселман дөньясында үстек. Әтием - сугышта булган кеше, штрафбат белән китеп, могҗиза белән исән-сау кайткан. Аларны сафка бастырып: “Арагызда повварлар бармы?” - дип сорыйлар, берәү дә дәшми. “Татарлар бармы?” - диләр. “Әйе”, - дип әти алга чыга. “Менә, син повар булырсың” - дип, аны ашарга пешерергә билгелиләр... 1956 елны, мин тугач, әтиемне Ростов-на-Дону шәһәренә имам итеп җибәрәләр, без гаиләбез белән шунда күченәбез. Аннан, миңа җиде яшьләр булганда, әтине Пермь шәһәренә имам итеп билгеләгәч, шунда киттек. Өйдә - барысы да татарча, ризык хәләл. Мәктәптә исә - пионер, комсомол тормышы, бөтенләй капма-каршы дөнья кебек. Ураза тотмый микән дип, укытучылар су эчертә, витамин бирә торганнар иде. Мәктәптә мин бер дә ит ашамадым, балык кына ашыйм дия идем... Мин сәүдә техникумында укыдым, 5 нче поварлык разрядым бар. Аннан сиксәненче елларда аудиокассеталар бизнесына кереп киттем, беркадәр вакыттан соң намазга килдем, мәчетләр төзеттем. 2006 елда Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә күченергә карар кылдык - мөселман иле булу кызыктырды. Монда җинаятьчелек юк дәрәҗәсендә. Аннан, монда эшмәкәрләр өчен дә бик уңайлы - салым түләтмиләр.

**- Белүемчә, биредә сезнең үз бизнесыгыз бар, сез - “ДАН” компанияләре төркеменең президенты...**

- Әйе, күчемсез милек, туризм һәм ресторан бизнесы белән шөгыльләнәм. «Шан» туристик оешмабыз эшли, «Казан» дигән ресторанымы бар.

**- Бу ресторан турында да ишетмәгән кеше сирәктер... Татарстаннан кем генә бу илгә аяк басмасын, “Казан”да кунак булмыйча китми. Шунысы гаҗәпләндерә: сез үзегезнең янга килгән һәркемне кабул итәргә, кунак итәргә ничек өлгерәсез?**

- Әти-әниемнең һәрчак әйтә торган сүзе бар иде: “Кунак килгәндә, бәрәкәт килә”, - диләр иде алар. Мин чыннан да кешеләрне кабул итәргә, алар белән аралашырга яратам. Кечкенә чакта ук,

**- Сез - күп балалы гаиләдә үскәнсез,**

әтием мулла булгач, өйдә мәҗлесләр булуга ияләшеп үстем бит. Андый мәлләрдә вәгазьләр укыла иде, дин, тел әнә шул рәвешле дә сакланып килгән инде. Мин биредә татар ассоциациясен дә җитәклим. Гарәп Әмирлекләрендә 400 меңләп рус телле халык яши, аларның 10 проценты татарча сөйләшә. “Казан” ресторанында дусларымны, танышларымны, милләттәшләремне җыярга тырышам. Танылган кешеләр кунакка килгәндә, иҗади очрашулар да оештырабыз. Татарлар белән ифтар ашларында, Корбан бәйрәмендә җыелабыз.

**- Сез - күп балалы гаиләдә үскәнсез, үзегез дә 11 бала әтисе. Интернет челтәреннән карап барганнар аларның чип-чиста итеп татарча сөйләшүенә игътибар итми калмыйдыр. Чит җирдә яшәп тә, туган телгә, дингә шундый ихтирамлы мөнәсәбәтегез сокландыра.**

- Гаиләбездә тулысынча татар мохите. Шул ук вакытта һәр балам кимендә дүрт тел - татарча, русча, инглизчә, гарәпчә белә. Татар телен укыту өчен Казаннан, Уфадан махсус мөгаллимнәр чакыртабыз. Балаларым Татарстанда, башка төбәкләрдә узган төрле чараларда да еш катнашып торалар. Минем “Воспитание детей мусульман в светском государстве” дигән китабым бар - мөселманнар тирәсендә формалашкан стереотипларны үзгәртү ниятеннән дә язылды ул. Намазда дигәч, балаларны җәмгыятьтән аерылган, бу дөньядан читләшкән дип күзаллаучылар да бар. Балаларны шәригать кануннарына нигезләнеп, милләтебезнең гореф-гадәтләрен сеңдереп тәрбияләгәндә, алар намазлы да, яңа белемнәргә ачык карашлы, туган телгә, дингә ихтирамлы булып үсәләр.

**- Исмәгыйль әфәнде, сезгә балаларыгыз, оныкларыгыз игелегенә тиенеп яшәүне, бүгенгедәй, гомерегезнең һәр көнен “Аллага шөкер” дип сөенеп үткәрүегезне телим!**

*Әңгәмәдәш - Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА.*

# Минем фикер

***Равилә ИСЛАМОВА, эшмәкәр (“Хәләл-Үзәк”тәге мөселман хатын-кызлары кибете):***

Безнең телэгебез сату итү генә түгел. Үзебездән күлмәк-яулык алып киткән кызларның исламга тартылуын, мондый киемнәргә карата аларда мәхәббәт уянуын телибез. Әйтик, никах күлмәге алырга дип килгән кызлар арасында төрлесе очрый. Гомерендә озын күлмәк кимәгән, яулык ябып карамаганнар да була, андыйлар өчен мондый киемнәрне кию үзе бер вакыйга. Шул мәлдә озын күлмәкнең матурлыгын, беренче тапкыр яулык япкач, үзенең хатын-кыз буларак өр-яңа яктан ачылганын күреп, ул кызда алга таба шушы рәвешле киенү теләге уянырга мөмкин. Икенче берәүләр үтеп-сүтеп йөргәндә озын күлмәкләргә кызыгып кына китәргә мөмкиннәр. Андыйларның йөзендә-сүзендә кызыксыну күрсәк, “Әйдәгез, киеп карыйбыз”, - дип үзебез ярдәм кулы сузабыз. Без Аллаһ ризалыгы өчен эшлибез, әгәр кемгә дә булса исламга килергә булыша алабыз икән, сөенәбез генә. Бервакыт бер кыз шулай бездә матур итеп киенеп китте, аннан мәчеткә йөри башлады, намазга басты, әлхәмдүлиллаһ!

Кайбер кызлар, мөселманча киенергә теләп тә, озын күлмәк киярга, яулык ябарга батырчылык итми йөриләр. Без андыйларга туникалар, тюрбан тәкъдим итәбез. Башта шулай киенәләр, аннан тора-бара күлмәк-яулыкка күчәләр. Чөнки бар нәрсә гыйлем белән килә. Иң мөһиме - теләк булсын! Минем үземнең мөселман кибетендә эшләргә теләгем бар иде, менә бит, Аллаһ үзем теләгәнне хәттә күбрәк итеп бирде. Башкаларны да ислам юлына бастырырга ярдәм итәрлек мөмкинлек бирде, Аллага шөкер!




*Балалар өчен*

## ИХЛАСЛЫК

Ихласлык булсын синдә,
Минем татлы сабыем!
Үз өстеңдә эшлә көн дә,
Бел шуны, балакаем!
Ихласлык булсын синдә,
Минем былбыл кошчыгым!
Аллаһтан сора көн дә,
Үтәр Раббым йомышың.
Ихласлык булсын синдә,
Минем Аллаһ бүләгем!
Аллаһ мәрхәмәтле безгә,
Бел тормышның кадерен.

**Алинә ХӘБИБУЛЛИНА,**
**“Асыл зат” төркеме җитәкчесе.**


**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**
**Баш мөхәррир**
**Айгөл Абдуллина**
**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45
* * *
**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, “Ислам нуры” дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның “Ислам нуры”ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән хатларда авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
islamgazeta@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

“Роспечать” агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы: 1350**
**Индексы 54149**


* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, тапшырсагыз иде. “Ислам нуры”ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.


* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән “Ислам нуры” басмаханәсендә басылды.

Нәшир һәм редакция адресы:
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды:**
**график буенча**
**26 февраль 16 сәг.**
**фактта 26 февраль 16 сәг.**
**Бәясе ирекле**